| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

________06.05.2019____ _458-п

Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалары булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланган өчен бер мәртәбә түләүнең старт күләмен исәпләп чыгару тәртибен раслау турында

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 40 статьясы, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер мәртәбә түләүнең старт күләмен билгеләү методикасын раслау турында» 2008 елның 30 сентябрендәге 232 номерлы боерыгы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалары булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрен файдалану хокукын бирү турында карарлар кабул итү буенча вәкаләтләрен тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалары булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланган өчен бер мәртәбә түләүнең старт күләмен исәпләп чыгару тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.
2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Т.Р.Гыйлаҗевка йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2019 елның «06» 05. № 458-п боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалары булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланган өчен бер мәртәбә түләүнең старт күләмен исәпләп чыгару тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмалары булган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланган өчен бер мәртәбә түләүнең старт күләмен исәпләп чыгаруның әлеге тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар уздыру шартларын әзерләгәндә (алга таба – җир асты байлыклары кишәрлекләре) Татарстан Республикасы территориясендә гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм табу яки гомумтаралган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм табу өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдаланган өчен бер мәртәбә түләүнең старт күләмен (алга таба – бер мәртәбә түләү күләме) исәпләп чыгару принципларын билгели.

1.2. Бер мәртәбә түләү күләме аукцион уздырыла торган һәр җир асты кишәрлеге буенча җир асты кишәрлегенең хакын бәяләү нигезендә билгеләнә.

1.3. Бер мәртәбә түләү күләме файдалы казылманың төрен, аның күләмен, җир асты байлыклары кишәрлекләренең геологик өйрәнелү дәрәҗәсен һәм урнашкан урынының географик-икътисадый шартларын исәпкә алып билгеләнә.

1.4. Җир асты кишәрлегендә файдалы казылмаларның берничә төре булган очракта бер мәртәбә түләү күләме файдалы казылманың һәр төре буенча исәпләнә, шуннан соң алынган нәтиҗәләр кушып куела.

## 2. Җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына аукционнар уздыру шартларын әзерләгәндә бер мәртәбә түләүнең старт күләмен исәпләү

2.1. Бер мәртәбә түләүнең старт күләмен билгеләү өчен түбәндәге исәп-хисаплар башкарыла:

- әлеге Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлекләрендә җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен бер мәртәбә түләүнең минималь старт күләме (алга таба – бер мәртәбә түләүнең минималь старт күләме);

- әлеге Тәртипнең 2.3 пункты нигезендә җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлегенең файдалы казылма запаслары күләмен, геологик өйрәнелгәнлеген һәм географик-икътисадый торышын исәпкә алып, бер мәртәбә түләүнең старт күләме.

2.2. Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен аукцион уздыру шартларында минималь сыйфатында билгеләнгән бер мәртәбә түләү мәгънәсе бер

мәртәбә түләүнең минималь старт күләме була.

Бер мәртәбә түләүнең минималь старт күләме файдалы казылмаларны табуга салымның исәпләмә суммасының 10 проценты күләмендә билгеләнә һәм киләсе формула буенча исәпләп чыгарыла:

**$РП_{мин}$ = $НДПИ_{год}$ x 0,1**,

биредә:

**$РП_{мин}$** – җир асты байлыкларыннан файданалган өчен бер мәртәбә түләүнең минималь старт күләме, мең сум;

**$НДПИ_{год}$** – табучы оешманың уртача еллык проект куәтенә исәплəгәндә файдалы казылмаларны табуга салым суммасы (алга таба – файдалы казылмаларны табуга уртача еллык салым суммасы), мең сум.

Файдалы казылмаларны табуга салым суммасы түбәндәге формула буенча билгеләнә:

**$НДПИ_{год}$ = $Ц_{пи}$ x $V_{ср}$ x $С_{НДПИ}$** ,

биредә:

**$Ц_{пи}$** – табыла торган файдалы казылма берәмлегенең Россия Федерациясе Салым кодексында каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, уртача бәяләрдә билгеләнгән бәясе, сум.

Табыла торган файдалы казылма берәмлегенең бәясе агымдагы елның 30 июненә һәм 31 декабренә аукцион игълан итү датасыннан алдагы 6 айлык чор өчен аны сатуның уртача базар бәясе буенча билгеләнә.

Табылган файдалы казылманы сатуның уртача бәясе Дәүләт статистикасының федераль хезмәте белешмәләре буенча Идел буе федераль округы буенча табылган файдалы казылма җитештерүчеләр бәяләре турында мәгълүматлар нигезендә билгеләнә.

Билгеләнә торган чорда югарыда аталган мәгълүматлар булмаган очракта, табылган файдалы казылма җитештерүчеләр бәяләре турында белешмәләр алдагы чор өчен алына.

Билгеләнә торган һәм алдагы чорлар өчен Идел буе федераль округы буенча табылган файдалы казылманы сатуның уртача бәясе турында белешмәләр булмаган очракта, әлеге мәгълүматлар Россия Федерациясе буенча алына.

**$V_{ср}$** (мең тонна, мең куб. метр) – табучы оешманың уртача еллык куәте (казылманы эшкәртү срогы өчен файдалы казылманы уртача еллык табу күләме), файдалы казылманың һәр төре өчен исәпләп чыгарыла.

Файдалы казылма запасларының исәпкә алынган дәүләти һәм (яки) территориаль балансы белән җир асты кишәрлекләре өчен табучы оешманың уртача еллык куәте (казылманы эшкәртү срогы өчен файдалы казылманы уртача еллык табу күләме) түбәндәгечә билгеләнә:

– дәүләт экспертизасын узган һәм билгеләнгән тәртиптә расланган файдалы казылма запасларын исәпләү өчен кондицияләрне техник-икътисадый нигезләү материаллары буенча (гомумтаралган файдалы казылма запасларын исәпләү өчен кондицияләр һәм гомумтаралган файдалы казылма запаслары дәүләт экспертизасын узган һәм билгеләнгән тәртиптә расланган булса);

– эшкәртүнең рентабельле булуын күрсәтүче һәм запасларны исәпләү материалларында күрсәтелгән, ләкин дәүләт экспертизасын узмаган һәм билгеләнгән тәртиптә расланмаган ятмаларны эшкәртүнең техник-икътисадый күрсәткечләре (исәпләмәләр, бәяләү) (әгәр гомумтаралган файдалы казылма

запаслары гына дәүләт экспертизасын узган һәм билгеләнгән тәртиптә расланган булса).

**$С_{НДПИ}$** (%) – файдалы казылмаларны табуга салым ставкасы. Россия Федерациясе Салым кодексының 342 статьясының 2 пункты нигезендә билгеләнә.

2.3. Бер мәртәбә түләүнең старт күләме аукцион игълан ителгән вакытка күрсәтелә.

Бер мәртәбә түләүнең (РП) старт күләме файдалы казылма запасларының күләмен, геологик өйрәнелгәнлеген һәм җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең географик-икътисадый торышын исәпкә алып билгеләнә һәм киләсе формула буенча ачыклана:

**$РП = РП_{мин} \times К$,**

биредә:

**$РП_{мин}$** – бер мәртәбә түләүнең минималь старт күләме, мең сум.

**К** – җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлеген эшкәртү үзенчәлекләрен һәм шартларын исәпкә алучы исәпләмә төзәтү коэффициенты.

Исәпләмә төзәтү коэффициенты (К) бер мәртәбә түләүнең минималь старт күләме зурлыгына төрле фактларның йогынты ясау коэффициентларының тапкырчыгышы буларак киләсе формула буенча билгеләнә:

**$К = К_{зап} \times К_{изуч} \times К_{инфр}$,**

биредә:

**$К_{зап}$** – җир асты кишәрлегендә файдалы казылма запаслары күләмен исәпкә алучы коэффициент;

**$К_{изуч}$** – җирле әһәмияттәге җир асты кишәрлегенең геологик өйрәнелү категориясен исәпкә алучы коэффициент;

**$К_{инфр}$** – төп географик-икътисадый факторларны исәпкә алучы коэффициент.

Җир асты кишәрлегендә файдалы казылма запаслары күләмен исәпкә алучы коэффициент ($К_{зап}$) 1 нче таблицага туры китереп билгеләнә:

1 нче таблица

| Җир асты кишәрлегендә запасларның (ресурсларның) үлчәнеше | Коэффициент мәгънәсе |
|---|---|
| Бик эре (5.0 млн. куб.метрдан артык) | 5,0 |
| Эре (2.5 млн куб метрдан алып 5,0 млн куб метрга кадәр) | 4,0 |
| Уртача (1,0 млн куб метрдан алып 2,5 млн куб метрга кадәр) | 3,0 |
| Вак (0,5 млн куб метрдан алып 1,0 млн куб метрга кадәр) | 2,0 |
| Бик вак (0,5 млн куб метрга кадәр) | 1,5 |

Запаслары булган җир асты кишәрлекләре өчен $К_{изуч}$ коэффициенты һәм каты файдалы казылмаларның фаразланган ресурслары киләсе формула буенча санап чыгарыла:

$К_{изуч} = (К_{iABC1} \text{ х } РБ_{ABC1} / РБ_{сумм}) + (К_{iC2} \text{ х } РБ_{C2} / РБ_{сумм}) + (К_{iP1} \text{ х } РБ_{P1} / РБ_{сумм}) + (К_{iP2} \text{ х } РБ_{P2} // РБ_{сумм}) + (К_{iP3} \text{ х } РБ_{P3} / РБ_{сумм})$,

биредә:

$К_i$ – запасларның тиешле категориясе һәм фаразланган ресурслар өчен тиешле коэффициент. $К_i$ коэффициентының мәгънәләре 2 нче таблицада китерелде:

2 нче таблица

| Өйрәнгәнлек категориясе | $К_i$ коэффициентының мәгънәләре |
|---|---|
| $P_3$ | 1 |
| $P_2$ | 2 |
| $P_1$ | 3 |
| $C_2$ | 4 |
| $ABC_1$ | 6 |

$РБ_х$ – запасларның һәм ресурсларның тиешле х категориясе өчен ресурс базасы;

$РБ_{сумм}$ – кишәрлекнең гомуми ресурс базасы, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$РБ_{сумм} = A + B + C_1 + C_2 + P_1 + P_2 + P_{3.}$

Җир асты кишәрлеге урнашкан районның географик-икътисадый шартларын исәпкә алучы коэффицент ($К_{инфр}$) мәгънәсе 2,0 тигез итеп кабул ителә.

2.4. Әлеге Тәртип таләпләренә туры китереп исәпләп чыгарылган бер мәртәбә түләү күләме зуррак якка дистәләрчә сумга кадәр түгәрәкләндерелә.